КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 декабрь г.Казань № 1153

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Бөгелмә муниципаль районындагы «Маяк» билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптацияләү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 1 февраленнән 423230, Татарстан Республикасы, Бөгелмә шәһәре, Якупов урамы, 38 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Бөгелмә муниципаль районындагы «Маяк» билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптацияләү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – «Маяк» үзәге) бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

14 көн эчендә:

«Маяк» үзәгенең ликвидация комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә «Маяк» үзәген бетерү тәртибен һәм срокларын билгеләргә;

эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә «Маяк» үзәгенең бетерү процессында булуы турындагы мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен терки торган органга бирергә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә бетерелә торган учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез мөлкәтен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне, шулай ук күчемсез мөлкәт объектларына техник документацияне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

гражданнарны «Маяк» үзәгеннән социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренә законнарда билгеләнгән тәртиптә күчерүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә бетерү аркасында азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә, шулай ук «Маяк» үзәген бетерү буенча законнарда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. «Маяк» үзәге йөкләмәләре буенча, шул исәптән суд карарларын үтәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына ике ай эчендә элек «Маяк» үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан бирелгән исемлек нигезендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.

5. «Маяк» үзәген бетерү чараларын үткәргәннән соң янга кала торган акча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Казан шәһәре» шәһәр округындагы «Милосердие» билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптацияләү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең кайка егәрлеген 25 урынга һәм персонал санын 24 штат берәмлегенә арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә бу карарның 2 пунктында күрсәтелгән барлык чаралар тәмамланганнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 4 октябрь, 948 нче карарына тиешле үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин